**МБОУ «Шеморданский лицей «Рост»**
**Сабинского муниципального района Республики Татарстан»**

# Описание опыта новых форм воспитательной деятельности в соответствии с номинации: «Воспитательные траектории детских общественных организаций, объединений» - «Новые формы организации социально-значимых мероприятий»

**Педагог-организатор:**
**Залина Ренатовна Сенгатуллина**

**Шеморлан, 2022 год**

## Введение

«История – наследство, урок, незаконченный процесс, словно вечный закон… Не зная истории, мы не можем понять, зачем мы пришли на этот свет, зачем мы живём, к чему стремимся» - писал В. С. Ключевский.

В последнее время прослеживается тенденция к снижению общего уровня культуры нашего общества. На первый план выходят меркантильные, материальные запросы человека, стремление жить в достатке, не задумываясь о том, какими средствами это благополучие достигнуто.

**Актуальность** данной темы обусловлена тем, что в это непростое время, наша задача сохранить в душах детей уважение к истории своей семьи, страны и малой Родины. Воспитать патриотические чувства, гражданские качества личности на уроках и внеклассных занятиях.

**Цель:** проведение общешкольного мероприятия на базе МБОУ «Шеморданский лицей «Рост» Сабинского муниципального района РТ» «Литературное кафе». Данная форма мероприятия сочетает в себе элементы литературного кафе, и более подробно отвечает информационным и социально-культурным запросам учеников лицея

**Задачи:**

- Создание оригинального пространства в виде литературного кафе, где ученики лицея смогут насладиться книгами, пообщаться, участвовать в мероприятиях.
- Совершенствование системы школьных мероприятий, внедрение новых нестандартных форм и методов работы.
- Создание пространства для проведения досуга для людей разного возраста, формирование социальной среды общения.
- Вовлечение молодежи в общественную жизнь школы, продвижение книги и чтения в молодёжной среде.
- Изучение истории, обеспечение информационной поддержки учеников лицея.

**Инновационность:** данный формат мероприятия «Литературное кафе» необычен по нескольким причинам:

- Обычно общешкольные мероприятия проводятся в актовом зале, а литературное кафе мы проводим в библиотеке, т.е. каждый зритель может почувствовать себя участником мероприятия
- События разворачиваются в нескольких шагах от зрителя
- Создаётся обстановка камерности. Больше доверия, легче раскрыться, духовная близость со зрителем, комфорт.

**Обоснованность данной формы:**

- Для наилучшего восприятия мероприятия
- Для глубокого погружения в историю происходящею на сцене, нужно быть не просто зрителем, а участником

Это возможно в случае, если форма мероприятия не просто концерт, не просто вечер, а литературное кафе, где и артисты, и зрители находятся в данной обстановке.

Используя новые формы воспитательных практик, с помощью литературного кафе историю можно увидеть своими глазами. А часто даже и потрогать своими руками. Таким образом, ответственность, лежащая на организаторах мероприятия очень велика, ведь от того, как проходят мероприятия, чаще всего зависит восприятие и осознание нашей истории, наша задача сохранить в душах детей уважение к истории своей семьи, страны и малой Родины. Воспитать патриотические чувства, гражданские качества личности.

**Внеклассное мероприятие:** Литературное кафе «Атылган йолдызлар яктысы».

**Авторы сценария:** Сенгатуллина Залина Ренатовна педагог-организатор, Шакирова Лейсан Накиповна библиотекарь Шеморданского лицея «Рост».

**Участники:** активисты Шеморданского лицея «Рост».

## Аннотация

Новая форма организация социально-значимого мероприятия в МБОУ «Шеморданский лицей «Рост» направлена на сохранение в душах детей уважения к истории своей семьи, страны и малой Родины, воспитание патриотических чувств и гражданских качеств личности. В ходе реализации

данной работы обучающийся научится слушать и убеждать собеседника, публично выступать, работать в команде, создавать и презентовать проект.

Актуальность заключается в инновационном воспитательном подходе при проведении мероприятия в виде литературного кафе. Такой формат способствует лучшему восприятию события, глубокому погружению в историю через происходящее в нескольких шагах от зрителя. Каждый участник мероприятия может почувствовать себя героем события, так как из-за камерной обстановки участникам легче раскрыть свои таланты, влиться в доверие и создать духовную близость со зрителем.

Данная новая форма воспитательных практик соответствует требованиям Федерального Закона об образовании в РФ, требованиям ФГОС и направлением развития национального проекта «Образования»: «дополнительное образование подростков и молодежи обеспечивает их адаптацию к жизни в обществе», «воспитание целостной, гармоничной и успешной личности».

Используя новые формы воспитательных практик, с помощью литературного кафе историю можно увидеть своими глазами, а иногда даже и потрогать руками. Для наилучшего восприятия происходящего на сцене, для глубокого погружения в историю, нужно быть не только зрителем, а участником. Это возможно лишь тогда, когда зрители и участники находятся в единой атмосферной обстановке.

**Ход мероприятия:**

*Зал кафе формасында бизәлгән. 4 өстәлдә 4әр кеше утыра. Һәркайсында шәмнәр яна. Подставкаларда әдәби меню. Менюда Х.Туфан, И.Салахов, К.Тинчурин иҗатларыннан өзекләр. Салфеткалар рәвешендә куелган битләрдә фактлар. Һәр өстәлдә кечкенә кыңгыраулар; шул кыңгырауларны шалтыраткач «официантлар» чыга.*

**Администратор-1:** Исәнмесез, хәерле көн, хөрмәтле әдәбият сөюче яшь дусларыбыз! Сезне «Хәтер» әдәби кафесында күрүебезгә чиксез шатбыз.

Урамда көз. Шак-шык, шак-шык көзге яңгыр тәрәз чиртә. Әллә көзге яңгырданмы, әллә җылы якка киткән кошларны сагыныпмы - никтер ямансу; йөрәк сыкрый, күңел нәрсәдер көтә, өзгәләнә. Шак-шык…шак-шык… Гүя тәрәзәгә шулай шакып көзге көндә хәтер йөри сыман. Хәтер... хәтер...

**Администратор-2:** Хәтер һич тә үткән генә түгел
Ул бит әле киләчәгең дә.
Юккамыни, бишегендә сыман,
Орлык ята гөл чәчәгендә.

Хәтер - синең кара урманнарда
Адашып юл эзләп йөрүләр.
Элек еллар хаксыз рәнҗетелгән
Асыл затлар - бөркет кебекләр.

Һәммәсе дә хәтер, бары - хәтер.
Бары хәтер сине дәвамың…
Каннан канга күчеп сиңа җиткән
Үҗәтлеге синең бабаңның.

Кеше шушы хәлдән таш гасырга
Кайтып төшмәсен дип яңадан
Хәтеремнән, бары хәтеремнән
Хикмәт табып, гыйбрәт ала алам.

**Администратор-1:** 30 октябрь - илебездә хәтер көне. Бу көн - политик репрессия корбаннарын искә алу көне буларак бөтенхалык тарафыннан билгеләп үтелә. Күп еллар дәвамында һәр шәһәрнең, һәр авылның тынычлыгын алып, нахакка рәнҗетелгән зыялы халыкның тозлы күз яшьләре, кайнар каны, кешегә бер генә бирелә торган гомерен кискән каргышлы, газаплы чорларны эченә алган 20 нче гасыр инде тарихка кереп бара. Әмма без ул елларның ачы фаҗигасен кичкән

буын балалары. Бик күпләребезнең газиз кешеләре - кемнәрнеңдер әби-бабасы, кемнәрнеңдер кан-кардәше, кемнәрнеңдер нәсел башы шул коточкыч давыллы еллар белән бәйледер. Бәйледер, чөнки, официаль булмаган тарихи чыганакларга караганда, 1917 нче елдан 1953 нче елга кадәр генә дә 6 миллионга якын алдынгы карашлы зыялылыр хөкем ителгән. Һәм шуның 800 меңгә якыны «атарга» дигән хөкем карары астында юк ителгән. Ә күпмесе төрмәләрдә, Колыма, Караганда, Магадан туфрагында, ГУЛАГ лагерьларында үлеп калган?! Алар арасында-атаклы галимнәр, язучылар, музыкант-рәссамнар, артистлар, хәрби начальниклар, укытучы, врачлар – кыскасы алыштыргысыз интеллегенция вәкилләре дә бик күп.
**Администратор-2:** …Ышанам, сезнең зәнгәр күктә атылган йолдызлар яктысын күргәнегез бардыр. Йолдызлар атыла, әмма алар артыннан якты эз кала. Без нахакка рәнҗетелеп, юк ителгән илдәшләребезнең язмышын да шул атылган йолдызлар яктысына тиңләп, бүген узегезне «Хәтер» кафесының «Атылган йолдызлар яктысы» дип аталган көндезге әдәби ашына чакырдык.

*Официантлар чыга.*
**Официант-1:** Хәерле көн! Безнең бүгенге менюда:
«Чынбарлык» - тозлы салат.
Репрессияләнгән язучыларның иҗатыннан кайнар аш - солянка.
Әдәби рагу - истәлекләр.
Десертка «Кайтаваз» коктейле.
*Официант-2 поднос белән «салат» өләшеп чыга.*
**Официант-2:** Әдәби ашыгыз бәрәкәтле булсын!
**Зилия:** - Ашның бәрәкәте бергәлектә. Бергә булсын!
**Официант-2:** Хөрмәтле кулланучыларыбыз! Сезгә тәкъдим ителгән салатыбыз-гадәти дә, жиңел дә түгел. Беренчедән – ул әдәби салат; икенчедән - ул, репрессия корбаннарын искә алу көненнән әзерләнде. Исеменнән күренгәнчә, документаль чыганаклардан,үтарихи вакыйгалардан торган салатка куп фактлар салынды. Тәкъдим итү - бездән, кабул итү сездән!
**Ильмир:** Тарих шахит:

Бик болганчык, авыр еллар булган-

Буран узган, илләр туздырылган.

Әрнү катыш тозлы күз яшьләре,

Һәм… кеше каны җиргә коелган.

Озак еллар һич тынмаган давыл -

Зыялылар илдән сорелгән.

Ул чакларда ал кояштан тугел -

Таң яралган кара сөремнән.

**Алинә:** Шомлы еллар һәм репрессия. Репрессия - аның иң котырган чагы - 37-38 нче елларга туры килсә дә, дөреслектә инде ул 1918 елда үк башлана. Һәм шул елны ук 3000 дин әхеле кулга алынып, һәммәсе дә атып үтерелә.

**Илсаф:** Репрессиянең икенче кайнар дулкыны хезмәт сөюче тырыш крестьян хуҗалыкларын туздыра. Үз көчләре белән күтәрелгән, урта хәлле гаиләләр дә «кулак» исеме астында, салкын Себергә сөреләләр. Аларның барлык җирләре, мал-байлыклары, йортлары тартып алына. Гаиләләр яңа туган нәни балаларын бишмәт эченә яшереп, бер кат кием белән, туган җирләреннән куыла. 1931 нче елга мондый гаиләләрнең саны 381 026 га җитә; 1 803 392 кеше йорт-җирсез кала. 1932-40 еллар эчендә аларга тагын «кулак» ярлыгы тагылган 489 822 кеше өстәлә.

**Эльвина:** Статистиканын официаль мэгълуматлары буенча, репрессиянен ин канкойгыч чоры-37-38 еллар. Ул чакта кулга алынган «халык дошманының» саны - 1 млн 520 меңгә җитә; шуларның 700 меңе ату җәзасына хөкем ителә.

**Әдилә:** Урындагы хуҗаларның башбаштаклыгы һәм явызлык дәвам итә. Органнарның үтә яшерен мәгълүматларына караганда, 1938-41 нче елларда «халык дошманы» дип кулга алынган 38900 кешенең 35000 е атып үтерелә.

**Администратор-1:** Миллионнар белән исәпләнгән репрессия корбаннарының төгәл генә санын хәзергә кадәр берәү дә белми. Нахакка рәнҗетелеп, гаиләсеннән, иленнән, җиреннән аерылып, «халык дошманы» исеме астында юк ителгән зыялы, затлы шәхесләрнең хәтта каберләре дә билгесез. Ул елларның гыйбрәтле язмышын дәлилләп, яңа каберлекләр ачыла. Мәсәлән, Карелия урманнарына

сыенып утырган Аю тавы итәгендәге чокырда,1937 елның 27 нче октябрендә атып үтерелгән 1111 кешенең мәете булу ачыкланды. Һәркайсында башында пуля эзе. Ә аларнын кайтуын туган йортларында никадәр кеше өзелеп көткәндер?! Ә ул еллардан күмелми, һаман да җир өстендә калган кеше сөякләре азмы әллә,

Куеп булмый гөлләр аларга.
Ядкарь булып бары исемнәре
Хәтерләрдә кабат яңара.

**Официант-2:** Хөрмәтле кулланучылар, өстәлләрегезгэ тәкъдим ителгән тозлы салатнын вакыты чыкты.

**Ильмир:** - Бер генә минут.

Салатның тозымы, әллә күз яшеме -
Яндырыплар алды телемне.
Эй, Җир-Анам, мин үтенәм синнән -
Кабат шундый канлы ялгышлардан
Сакла, зинһар туган илемне!

**Официант-1:** Рәхмәт. Сезгә чираттагы тәкъдим ителәсе ризыгыбыз - репрессияләнгән татар язучыларның иҗатыннан кайнар аш - әдәби солянка.

*Өләшеп бетерүгә ишек шакымыйча, бик тупас 3 кеше (йолдызлы фуражка, кара пальто, күн сумка, күнитек кигәннәр) түргә үтә.*

**Администратор-1:** Гафу итегез, безнең кафе бүген бары чакырылган кунакларны гына кабул итә. Ялгыш кердегез. Без сезне түргэ үткәрә алмыйбыз.

**НКВД:** *(ирония белән көлеп)* Хе, а кто спрашивает у вас разрешение? *(кулындагы билетны курсәтеп)* НКВД. Укыйбыз, димәк. Кем китабы?

**Алинә:** Хәсән Туфан.

**НКВД:** Халык дошманы! Контр! 1940 нчы елның 18 нче ноябре Хәсән Туфан илгә һәм халыкка хыянәт итүдә, милләтчелектә, Япон шпионы булуда гаепләнеп, кулга алына. 1942 нче елның 7 нче мартында суд аны атып үтерүгә хөкем итә. Ознокомьтесь, приговор суда!

Враг народа! Контр! Уже в 1937 году Хасан Туфан исключен из Союза писателей. 18 ноября 1940 года он был арестован. 7 марта 1942 года за измену

Родины, за шпионаж в пользу Японии  его приговорили  к высшей мере наказания – расстрелу  с конфискацией всего личного имущества.

**Эльвина:** Җилләр исә исәр-исмәс кенә,
Чәчәк сибелә сибелер-сибелмәс...
Уйлады ул: беркем белмәс инде
Шулай яшерен һәлак ителгәч.

Ике кулын артка куйган килеш
Үтеп бара алан үтәли.
Сабыр гына искән урман җиле
Айлы юлга чәчәк сибәли.

Ә сандугач никтер уйга талган,
Дәшми кошчык,күңеле тулган күк.
Кәккүк кенә кайчак үксеп куя,
Елап арыган ятим олан күк...

Ул баш иеп уза
Имән картка,
Сеңелләр күк сылу каенга.
Горизонттан кояш килеп чыга
Бәхилләшеп, күреп калырга.

Китеп бара
Устав боерганча
Артка куеп
Бәйле кулларын,
Югыйсә, ул сыйпап узар иде
Боегып торган балан куагын...

Винтовкасын озак төзи җәллад:
Йөрәк турысын эзли шикелле...
...Әллә шунда
Кошлар кычкырдылар,
Әллә аңа шулай ишетелде:

Тыныч кына әйтте:
-Башыма төбә.
Минем җаным шунда – башымда.
Туган илен өзелеп сөйгән өчен
“ Гаепле” ул палач каршында.

Уйлады ул:
-Шулай яшерен үлгәч,
Кем белсен,- дип,-соңгы хәлемне...
...Үксеп искән җилдә чәчәк сибелә,
Чәчәк күмә
Яңа каберне...

**НКВД:** 21 нче март, 1942 нче ел. СССР Югары судының Хәрби коллегиясе Хәсән Туфанның эшен яңадан карап, үлем карарын 10 елга лагерьга җибәрү һәм тагын 5 ел сәяси хокуклардан мәхрүм ителү белән алыштыра.

**НКВД:** Контр! Халык дошманы! Срогы тулганнан сон, Хәсән улын Туфанны гомерлек сөргенгә озатырга! Гаиләсен, Илен, туганнарын күрүдән мәңгелеккә мәхрүм итәргә!

**Администратор-2:** Хәсән Туфанның тоткынлык дәвере 16 елга сузыла. Сталин үлеп, аның сәясәтендәге җитди хаталары ачылганнан соң гына, шагыйрьгә иреккә чыгарга мөмкинлек туа. 1956 нчы елның җәендә ул Казанга кайта. Ләкин өенә

кайтканда аның узеннэн 4 айлык булып калган улы, һәм күп җәбер-газаплар күреп, нахакка рәнҗетелгән хатыны да үлгән була инде.

**Ильмир:**

Дөнья мине
Үзгәртте:
Еламаска өйрәтте.
Күлмәк җиңен ертасымы?-
Бәйлисе бар
Йөрәкне.
Сугышлардан замана
Туктап торган арада,
Яраларны ямаштырып
Ята идем
Далада:
-Кайт!..- дип хатлар килделәр...
Юллар... озын иделәр...
Кайттым.
-Бусы алкалары,
Бусы - кабере...- диделәр.
Әгәр тагын килсәләр:
-Сау! – дип хәбәр бирсәләр,
Вулканнарга керер идем,
Шундадыр ул... дисәләр.
Бирде дөнья кирәкне,
Еламаска өйрәтте...
Кайсыгызның кулы җылы?-
Бәйлисе бар йөрәкне...

*Звонок. Официант-1 чыга, икенче өстәлгә И.Салахов китабын куя.*

**Официант-2:** Рәхим итегез, Ибраһим Салахов.

**Илсаф:** *(китапны алып)* Ибраһим Салахов.

**НКВД:** *(өстәлгә сугып)* Враг народа! Предатель! «Ибрахим Салахов арестован 24 октября 1937 года.

Обвинение: разложение комсомольской организации, измена, шпионаж в пользу Японии.

Осужден: 12 мая 1938 г. Военной Коллегией Верховного Суда СССР.

Статья: 17-58, п. 8, 58, п. 11.

Приговор: 10 лет ИТЛ, конфискация имущества, поражен. прав на 5 лет.

**НКВД:** 58 нче статьяның беренче, жиденче, сигезенче, унынчы, унберенче, унҗиденче пунктлары буенча гаепләнеп, ун ел аерым режимдагы төрмәгә ябылу, һәм төрмә срогын тутырганнан соң, биш елга барлык гражданлык хокукларыннан мәхрүм калдырырга хөкем ителә»

**Илсаф:** -Ялган! Ял-ган! Ул һичбер вакытта да, һичбер вакытта да туган иленә хыянэт итмәгән! Хыянэт итмәгән, ишетәсезме?!

**НКВД:** *(өстәлгә сугып)* Молчать! Колымага!

**Илсаф:** …Мине муеныма «халык дошманы» дигән ярлык тагып, 10 елга Колымага озаттылар. Бервакыт, забойда ишелгән җир астында калып, нык имгәндем.

Бернинди наркозсыз-нисез, сул аягымны тубыктан кистеләр. Әмма икенче көнне үк гангрена башланды. Авыртуга чик-чама юк-температурам 40 тан артты, үз аягымнан килгән искә чыдый алмыйм - сасыган ит исе! Минем белән шахтада күмелгән тоткыннарның үле гәудәләрен утын өйгән кебек, әрдәнәләп, урамга өеп куйдылар. Дүртәү генә калдык. Шулчак, бер камерада утыручы тоткын миңа ярдәм итәргә алынды. Ул иректә чакта хирург булып эшләгән икән. Төрмә шартларында аның алтын кулы белән ясалган операциясеннән соң, атна узуга мин аякка бастым. Менә инде ничә дистә ел бер аягым Колыма җирендә мәңгелек туңда ята. Ничэ ел протез белән йөрим. Киселгән урында бер шеш, яра юк! Һәр көн иртән торып, протез киюгә. «Мең рәхмәт сиңа, ерактагы дус!»,- дип, мин аны искә алам!».

3че өстәл звонок бирә. Официант чыга. Өстәлгә китап куя. Фатих Кәрим иҗатын укып, җаныгызга күңел сафлыгы иңсен!

**Рамилә:** Фатих Кәрим.

**НКВД:** Контр! Враг народа! Националист! 1938 елның 3 январенда кулга алынды. Барлык кулъязмалары, китаплалары яндырылды! Үзен буржуазия ялчысы, кулаклар идеологиясен үткәрүче халык дошманы булганы өчен, 1939 елның 14 мартындагы ябык утырышта ун елга ирегеннән мәхрүм итәргә һәм, шуңа өстәп, тагын биш елга гражданлык хокукларыннан чикләргә дигән хөкем карары чыкты.

**Рамилә:** Дөрес тугел! Ул контр була алмый. Фатих Кәрим ил азатлыгын яклап, сугыш кырында 1945 нче елның Кенигсберг шәһәре янында батырларча һәлак була.

**НКВД:** Генерал Якуб Чанышев һәм язучы Кави Нәҗмиләрдән кергән күпсанлы гаризалар нигезендә, СССР Югары суды Фатих Кәримнең җинаять эшен кабат карый. Һәм... 1941нең декабрендә аны иреккә чыгара. Тик бер шарт белән: кайтуга ук, ул үз теләге белән фронтка китәргә тиеш!

*Официант чыга. Подноста китаплар.*

Кәрим Тиңчурин. Расстрелян 15 ноября 1938 года.

Афзал Тахиров. Расстрелян 27 сентября 1937 года.

Сәгыйть Сүнчәләй - в 1937 году.

Шамил Усманов арестован 8 апреля 1937 г. Приговорен: обв.:ст. 58-8, 58-11. («участник националистической султангалеевской организации»). Умер 3.12.37 в г. Казань, в кабинете зам. наркома внутренних дел ТАССР, во время допроса от «паралича сердца».

Суббух Рафиков. Арестован 17 октября 1937 г.

Приговор: 10 лет лишения свободы, конфискация имущества, поражен. прав на 5 лет.

Фатхи Бурнаш Арестован 24 августа 1940 года. Осужден Особым совещанием при НКВД СССР 15 июня 1942 года, расстрелян 1 августа 1942 года в Куйбышеве.

Аяз Гилязов. В 1950 году был арестован и сослан в карагандинский лагерь, где содержались даже лауреаты Сталинских премий. Там Гилязов находился пять лет.

Махмут Галяу. Обвиняется в причастности к татарским националистическим организациям. 14 ноября 1937 года он был расстрелян по приговору суда.

Арестован 2 июля 1937 г. Кави был помещён в одиночную камеру во дворе НКВД на «Чёрном озере», подвергался избиениям, круглосуточным допросам без воды и еды, психологическому давлению, сидел в карцере. Приговорён Судебной коллегией Верховного суда ТАССР 19 марта 1939 г., по обвинению по статьям 58-2, 58-10 ч.1, 58-11. («контрреволюционная деятельность на литературном фронте»). Приговор: 10 лет тюремного заключения, поражение прав на 5 лет, УНКВД ТАССР. 29.12.1939 дело было прекращено за недоказанностью обвинения. Наджми был освобождён накануне Нового 1940 года.

**Ильмир:** Бакый Урманче, Мирсәй Әмир, Гурий Тавлин, Галимҗан Ибраһимов…

**НКВД:** Хватит! Они все осуждены! У вас не хватит часы, чтобы пересчитать их имена! Всё, пошли!

*Куркыныч музыка. НКВД лар китәләр.*

**Илсаф:** Эйе, алар бар да нахакка рәнҗетелеп, хөкем ителгәннәр. Әмма бар да еллар үткәч, акланганнар.

**Официант-2:** Кайнар ашнын вакыты чыкты. Игътибарыгызга-бөек шәхеслэрнең истәлеккә калган иҗатларыннан әдәби рагу тәкъдим итәбез. Рәхим итеп кабул итегез, шифасы күңелләрегезгә нур булып ятсын!

**Җыр «Әйткән идең»**

*ДЕСЕРТ «КАЙТАВАЗ». Официантлар трубочкалар итеп төрелгән «десерт»ны өләшә. Аларда репрессия чорын яктырткан матур әдәбият исемлеге. Шул ук вакытта, «Төш» куренеше.*

**Зилия-Ильмир:** «Төш»

**Администратор-2:** Атылган йолдызлар яктысы… Әйе, йөзләгән, меңләгән йолдызлар атылган. Репрессиягә эләгеп тә, үзләреннән соң дистә, йөз елларга җитәрлек әдәби мирас калдырган әдипләр язмышын да без шул атылган йолдызларга тиңләп, мөгаен, ялгышмаганбыздыр.

1921–1953 нче еллардагы репрессияләр вакытында СССРда барлыгы 6 миллионнан артык кеше зыян күргән дип санала. Тик аларның саны, хатыннары, балалары, туганнары, дуслары дучар булган төрле мыскыллау-кыерсытылуларны да исәпләсәң, 60 миллионга да туладыр. Ә документлар буенча әлеге 6 миллион кешенең 4 миллионнан артыгы төрлечә җәзаланган, 800 мең кеше үлемгә хөкем ителгән. Зыян күрүчеләрнең 2,6 миллион тирәсе милләтчелектә гаепләнеп, 1 миллионнан артыгы эш сөюче крестьян булганы өчен "кулак" дип җәзаланган.

37 нче елның канлы тәгәрмәче, беренче чиратта, Татарстанга зур зыян китергән, милли-мәдәни үсешебезне озак елларга имгәтеп калдырган. Архив материалларына караганда, Татарстанда сәяси репрессия корбаннары 55 меңгә якын. Аларның биштән бере атылган я зинданнарда черетелгән. Әйтергә генә ансат: Татарстанда туган, яшәгән һәм 1918 — 1953 нче елларда сәяси репрессияләргә дучар булган корбаннарның исемлеге «Хәтер китабы» ның калын-калын 17 томын тәшкил итә. Мондый явызлыкны һич кенә дә онытырга ярамый, ил тарихындагы мәңгелек яра, җәрәхәт ул!

**Администратор-1:**

Безгә хәтер юкка бирелмәгән,
Яшәмәде халык хәтерсез.
Томаларга теләсә дә еллар -
Бәреп чыкты барыбер әйтер сүз.
Гөрләгән дә булды, дөрләгән дә,

Язып бара хәтер барын да.
Югалтырга безнең юк хакыбыз
Яманын да, яхшыларын да!
Мәкер өчен түгел безнең хәтер,
Зураймыйдыр һичкем үч алып.
Бүгенгесен, үткәндәген җуйса -
Киләчәктән мәхрүм ул халык.
Халык хәтереннән аерылганның
Яшәве дә әрәм, гел зая.
Азга гына килә җиргә кеше -
Хәтерләрдә гомер озая.
Яшерә алмас вакыт пәрдәләре,
Киткәннәр дә кире кайтырлар.
Безгә хәтер юкка бирелмәгән,
Югалмасын бары хәтерләр!

**Администратор-2:** 18 октября 1991 года было принято Постановление Верховного Совета РСФСР № 1763/1-I от «Об установлении Дня памяти жертв политических репрессий», после которого 30 октября стало официально признанным днём памяти.